11. *Tatar teleneң aңlatmaly syzlege* (1979) [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. Өch tomda. T. 2. 726 p. Kazan, Tatar kit. nәshr. (In Tatar)

12. Khanbikova, Sh. S., Safiullina, F. S. (1999). *Sinonimnar syzlege* [Dictionary of Synonyms]. 256 p. Kazan, Khәter. (In Tatar)

13. Cherneiko, L. O. (1997). *Lingvofilosofskii analiz abstraktnogo imeni* [Linguistic-Philosophical Analysis of an Abstract Name]. 320 p. Moscow. (In Russian)

14. Ziatdinova, G. I. (2010). *Kontsept "Sugysh (Voina)" v tatarskoi yazykovoi kartine mira* [The Concept "Sugysh (War)" in the Tatar Language Picture of the World]. 168 p. Kazan', Ikhlas. (In Russian)

15. Maslova, V. A. (2008). *Kognitivnaya lingvistika* [Cognitive linguistics]. 266 p. Minsk, TetraSistems. (In Russian)

---

# «СУГЫШ» ЛИНГВОМӘДӘНИ КОНЦЕПТЫНЫҢ ТАТАР МИЛЛИ АҢЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

**Гөлназ Иршат кызы Зыятдинова,**
А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ,
Россия, 420015, Казан ш., Б. Красная ур., 55 йорт,
ggulnaz0507@mail.ru.

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
alyusupova@yandex.ru.

**Фирүзә Рәмзил кызы Сибгаева,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
FiruzaRS88@ yandex.ru.

Аерым тел материалында төп мәдәни концептларны комплекслы анализлау, төрле лингвомәдәни традиция вәкилләрен, чынбарлыкны кабул итүдә универсаль һәм үзенчәлекле булуын ачыклау өчен кирәк. Мәдәни концептларның мөһимлеге – кулланылу ешлыгына карап билгеләнә. Алар үзенчәлекле яки әһәмиятле өлкәдә кулланылырга мөмкин һәм еш кына фразеологик берәмлекләр составына, мәкальләргә, әйтемнәргә, шигырь һәм җыр текстларына кертелә. Шуңа бәйле рәвештә «Сугыш» концептының мәдәни компонентын ачу зур әһәмияткә ия. Әлеге концепт, иҗтимагый-сәяси феномен буларак, татар телендә күпкырлы һәм вариатив билгеләмәгә ия. Бу күренешкә төрле фәннәр – тарих, сәясәт белеме, фәлсәфә, социология һ. б. – бик күп төрле билгеләмәләр бирә, хезмәтләр багышлый. Сугыш темасы әдәбиятта, сәнгатьтә дә зур урын алып тора, анда татар халкының тарихы һәм бүгенгесе чагылдырыла.

Татар телендә сөйләшүчеләр аңында «Сугыш» концептының урынын һәм ролен билгеләү кызыклы һәм әһәмиятле булып тоелды.

**Төп төшенчәләр:** сугыш, дөнья тел сурәте, лингвомәдәни концепт, милли концептосфера, татар теле

**Сылтама өчен:** Зыятдинова Г.И., Юсупова Ә.Ш., Сибгаева Ф.Р. «Сугыш» лингвомәдәни концептының татар милли аңында тоткан урыны // Tatarica. 2025. № 2 (25). 22–33 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-21-33

## Кереш

Тел чынбарлыкны чагылдырып кына калмый, ә аны интерпретацияли, кеше яши торган үзенчәлекле чынбарлык хасил итә. «Кеше, нигездә, үзе үк интеллектуаль, рухи, социаль ихтыяҗлар өчен иҗат иткән концептлар (менталь асыллыклар) дөньясында яши, чөнки аңа мәгълүматның шактый өлеше сүз аша килә, һәм кешенең җәмгыятьтә уңышы аның сүзне никадәр яхшы белүенә бәйле, сөйләм культурасы ягыннан гына түгел, бәлки тел серләренә үтеп керә белүгә дә бәйле» [1].

Тел галимнәре, антропологлар, тарихчылар, мәдәният белгечләре тарафыннан кешеләр тормышының мәдәният белән үзара бәйләнешенең телдәге чагылышы мәсьәләләрен интенсив өйрәнү әлеге проблеманы тикшерүдә лингвомәдәни алым барлыкка килүгә сәбәп була. Аның өчен телдәге мәдәни кыйммәтләр системасын нәзари һәм гамәли яктан, ягъни бербөтен итеп тасвирлау әһәмиятле.

Лингвомәдәният, фән буларак, XX гасырның икенче яртысында формалаша. В. И. Маслова лингвомәдәниятне «тел белеме белән мәдәният кисешкән урында барлыкка килгән һәм халык мәдәниятенең телдә чагылыш тапкан һәм ныгып калган чагылышларын өйрәнә» дип саный [1, б. 14].

Бүгенге көндә лингвомәдәни тикшеренүләрнең дүрт төп юнәлеше бар: 1) фразеологик (В.Н. Телия), 2) логик-лингвистик яки концептологик (Н.Д. Арутюнова, А. Вежбицкая һ. б.), 3) лексикографик (В.П. Руднев, Ю.С. Степанов һ. б.), 4) лингводидактик (В.В. Воробьев һ. б.) юнәлешләр.

Татар тел белемендә дөнья тел сурәте проблемалары Р. Р. Җамалетдинов хезмәтләрендә чагылыш таба. 2004 елда аның «Татарская культура в языковом отражении» дигән монографиясе басылып чыга. Хезмәт татар дөнья тел сурәтендә кешенең матди һәм рухи дөньясы фрагментларын концептлаштыру үзенчәлекләрен ачыклауга багышланган. Монография дөньяның татар телен сурәтләү проблемасын шактый киң яктырта һәм бу юнәлештә тикшеренүләргә нигез сала [2].

Кеше концептлар дөньясында яши. Концепт, С.А. Аскольдов, Е.С. Кубрякова, С.Х. Ляпин, О.П. Скиданның фәнни аңлатмаларына караганда, «дөньяны танып белү процессын, кеше эшчәнлеге нәтиҗәләрен, аның дөнья турындагы тәҗрибәсен һәм белемнәрен чагылдырган, аның турында мәгълүмат саклый торган күп үлчәмле фикер конструкциясе» [3, б. 40-59].

Аерым тел материалында төп мәдәни концептларны комплекслы анализлау төрле лингвомәдәни традицияләр вәкилләренең чынбарлыкны кабул итүдә универсаль һәм үзенчәлекле булуын ачыклау өчен кирәк. Шуңа бәйле рәвештә «Сугыш» концептының татар дөнья тел сурәтендә мәдәни компонентын ачу зур әһәмияткә ия. Әлеге концепт, иҗтимагый-сәяси феномен буларак, татар телендә күп һәм вариатив билгеләмәләргә ия.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Концептның мәгънәви күләмен билгеләү өчен, әлеге концептның нинди референт хәлгә керүен карарга кирәк. Тикшерү барышында лингвомәдәни анализ методы, сүзлек мәкаләсен анализлау һәм концептуаль анализ методлары кулланылды.

## Фикер алышу

Концепт – дефиницион характеристикаларны гына түгел, коннотатив, образлы, бәяләү, ассоциатив тасвирламаларны да үз эченә алган күп үлчәмле берәмлек. Саналган билгеләрнең барысы да концептны тасвирлаганда исәпкә алынырга тиеш. Концептлар элементар төшенчә эчтәлегеннән алып югары дәрәҗәдәге абстракциянең иң катлаулы концептуаль төзелешенә ия булган мәгълүматларны тапшырырга сәләтле.

Концептларны өйрәнү тематик, этимологик сүзлекләрдән башлана.

1926 елда басылып чыккан «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы» («Русско-татарский словарь военных терминов (толмач)») хезмәтендә хәрби өлкәгә караган лексиканы тәртипкә салу, системалап бирү эшендә тәүге тәҗрибә була. Аны төзүгә этәргән төп сәбәпләр итеп XX гасырның беренче чирегендә татар хәрбиләренең русчаны камил белмәүләрен низамнамәләр һәм хәрби документларны татарчага тәрҗемә итүдәге төрлелек, бу чорда шактый гына хәрби газеталарның нәшер ителүе һәм башка шундый факторларны күрсәтергә була. Сүзлекнең уңай

һәм әһәмиятле ягы анда туган телебез нигезендә терминнар ясау тәҗрибәсе өчен бүген дә игътибар итәрлек мисаллар теркәлүгә бәйле [4].

Р.А. Мөгыйновның 2000 елда нәшер ителгән «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге» – татар теленең хәрби лексикасын системалаштыруда иң җитди хезмәтләрдән берсе. 8 меңгә якын лексик берәмлекне эченә алган сүзлектә автор русча терминнарга аларның татарча тәңгәлләрен тәкъдим итү белән генә чикләнеп калмый, аңлатмалы сүзлеккә хас рәвештә күп кенә сүзләрнең мәгънәләрен дә бирә [5].

Э.В. Севортянның «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге» мәгълүматлары буенча [6, б. 290-291] сокуш-уйг. диал., согуш – алт. диал., согыс – каз., сугыш – тат., хугыш – баш.; көрәшү, сугышу, кыйнашу, бер-береңне төртү, сөзү, бәргәләшү (әтәчләр турында), бер-берең белән бәрелешү (йөгергәндә).

*-Мак* кушымчалы исем фигыль формасы белән ясалган сүзләр, -(у/ы)ш кушымчалары белән ясалганнарга караганда азрак: сокуш төрк. диал. – сугыш, яу, көрәш мәгънәсендә, сокаш уйг. диал. – сугыш, яу, көрәш мәгънәсендә, согуш кир., алт. диал. – сугыш, яу, көрәш, орыш, кыйнаш, кыйнау мәгънәсендә.

XIX гасырның татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрендә сугыш мәгънәсендә *сугыш* һәм *яу* сүзләре параллель рәвештә кулланыла. Ф.М. Хисамова сугыш лексемасы иске татар теленә генә хас дип билгели [7, б. 30]. Төрки телле язма истәлекләрдә ул бу мәгънәдә очрамый, ә борынгы төрки сүзлектә sönüs сүзе теркәлгән. XII-XIV йөзләрдәге «Урта Азия тәфсире» һәм «Огуз-намә» кебек язма истәлекләрдә сугыш мәгънәсендә *уруш* сүзе кулланыла. Ул Алтын Урда һәм Харәземнең язма истәлекләрендә теркәлгән [7, б. 33].

Хәзерге төрки телләрдән *сугыш* фонетик яңгыраште бары тик татар телендә генә кулланыла. Бераз башка фонетик яңгыраште ул уйгыр телендә – *сокуш*, казах телендә – *согыс*, башкорт телендә *һугыш* очрый.

Р.Т. Сәфәровның «Военная лексика татарского языка» (2015) дигән хезмәте хәрби лексиканы синхрон һәм диахрон аспектларда өйрәнүгә багышлана. Галим тарихи-генетик катламнарны ачыклый, хәзерге татар телендә хәрби лексиканың яшәеш үзенчәлекләре ачыклана [8]. Р.Т. Сәфәров тарафыннан 2017 елда «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» дә төзелә. Сүзлектә, нигездә, хәрби кораллар һәм корал төрләренең атамалары, аларның аерым өлешләрен, детальләрен, саклау савытларын белдергән сүзләр; саклану киемнәре һәм аларның аерым өлешләрен тәгъбирләгән берәмлекләр; төрле хәрби берләшмәләр, сугышчыларның исемнәре; гаскәр башлыкларының атамалары; сугыш мәйданының аерым эпизодларын, хәрби символларны белдергән берәмлекләр; әсирләрне тасвирлауга бәйле лексика һәм хәрби өлкәгә караган башка шундый сүзләр алынган. Кулланылыш үзенчәлекләре күрсәтелә, мәгънәләрен тулырак һәм төгәлрәк ачу максатыннан, һәр сүзгә, мөмкин булган кадәр күләмдә, иллюстратив материал бирелә [9].

«Миллият сүзлеге»ндә сугышның түбәндәге мәгънәләре китерелә: *Сугыш* – орыш, кыйнаш, тукыш, тукмаш; суеш; борынгы төрки телдә *сөңгеш* һәм *чәнчеш* сүзләре очрый. Татар әдәбиятында сугыш мәгънәсендә гарәп теленнән алынган *хәрб, газва* кебек сүзләр очрый [10, б. 395].

Лексик берәмлекләр, концептның башлангыч асылын татар телендә һәм тугандаш телләрдә номинация нигезенә салынган билге аша ача: *сугыш* – кораллы конфликт, яу, дау, кыйнаш, бәрелеш, көрәш, орыш. Күргәнебезчә, әлеге концептның дошманлык-милитаризм ассоциацияләре өстенлек итә, әмма шул ук вакытта уртак, тыныч эшчәнлек мәгънәсе дә бар – Э.В. Севортянның «Төрки телләрнең этимологик сүзлегендә» бер-береңә нәрсә дә булса талку, вакларга ярдәм итү мәгънәсе бирелә [8, б. 291].

«Сугыш» концептын тасвирлауның иң мөһим этабы – концептның төш элементын билгеләү. Бу очракта аңлатмалы сүзлек ярдәм итә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (ТТАС) *сугыш* сүзенең түбәндәге мәгънәләре бирелә: 1. Сугышу и. (2-4 мәгънә). «Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың» (На этих вечерах, конечно же, поешь, играешь «ударь по спине», в «колечко») (А. Шамов). 2. Бер-береңә сугу, кыйнаш ф. «Безнең бабай тирәсендә үзара сугышу, бәйләнешү, бер-береңне кимсетү-хурлау кая инде ул!» М. Гали. «Кикрикләрен канга батырып сугышып торган ике әтәч, куркып аның аяк астыннан икесе ике якка очты». (Г. Әпсәләмов). 3. Дәүләтләр, армияләр һ. б. ш. арасындагы кораллы көрәш. Ватан сугышы. Сугыш коралы. Гражданнар сугышы. // Шул көрәшнең аерым бер бәрелеше Штык сугышы. «Фронтларда сугышып йөрдем мин»

(Б. Рәхмәт) [11, б. 369]. Күргәнебезчә, сүзлектә *сугыш* лексемасының алты мәгънәсе китерелә. Сугыш хәзерге интерпретациядә дә дошманлык-милитаристлык мәгънәләрен саклауны дәвам итә, «социаль төшенчәләр һәм мөнәсәбәтләр» концептосферасын тәшкил итә торган берәмлек булып кала.

Ш.С. Ханбикова һәм Ф.С. Сафиуллинаның «Синонимнар сүзлеге»ндә без карый торган төшенчәнең түбәндәге синонимнары китерелә: *орыш, яу, дау, бәрелеш, үтереш, кан коеш, көрәш, кыйнаш* [12, б. 168].

«Сугыш» концепты репрезентаторы, *көрәш* лексемасы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә түбәндәге аңлатмаларга ия: 1. Ике кешенең көч кулланып икенчесен егарга тырышуы, үзра алышуы, бер-берсен җиңәргә тырышуы. «Нокта Вәлинең хәлдән таюы да минекеннән ким булмагандыр. Чөнки көрәшнең актыгына таба ул мине бернәрсә дә эшләтә алмый башлады» Ш. Камал. // Билгеле бер кагыйдәләр буенча алып барыла торган спорт уены, ике кеше көч сынашу. Татарча көрәш. «Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач...болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышлар башланды» (Г. Тукай). // Ярышу. «Җиңел атлетика буенча ярышларны караучылар ... дөньяның биеклеккә сикерүче иң яхшы спортчылары арасында барган кискен көрәшне оныта алмаслар» (Социалистик Татарстан). 2. Капма-каршы иҗтимагый төркемнәрнең, юнәлешләрнең һ. б. ш. хакимлеккә ирешү өчен, җиңеп чыгу өчен алып барган актив эшчәнлеге, аларның бәрелеше. «(Әсәрдә) вакыйга байлар белән ярлылар арасындагы көрәшкә нигезләнгән» (М. Гали) // Шул төркемнәргә, юнәлешләргә кергән аерым вәкилләрнең бәрелеше. «Фәхри белән Вәли Хасанов арасындагы көрәшне мин ике кешенең ызгышуы гына дип карадым» (Г. Ибрагимов). 3. Нинди дә булса бер максатка ирешү өчен алып барылган эш, шуңа юнәлтелгән актив эшчәнлек. *Шәхси борчулар артка чигенде, икмәк өчен көрәш,фронтны тәэмин итү өчен көрәш һәркайда беренче урынга килеп басты. Г. Бәширов.* 4. Сугыш, бәрелеш. *Көрәш әле шактый кызу барган чакта, Үрге Кигәвенле ягыннан ЧОН отряды килеп чыкты. Ш. Камал.* 5. *махс.* Үсеш процессына капма-каршыларның бәрелеше (табигатьтә, җәмгыятьтә). *Табигатьнең иркен күкрәгендә Мәңге көрәш, мәңге хәрәкәт.* 6. *күч.* Бер-берсенә капма-каршы булган хисләр, омтылышлар һ .б. ның бәрелеше. Хикәядә кешелектә булган «явыз» һәм «яхшы» холык көрәше, пассив күзәтүче карашыннан килеп, бер-беренә каршы куелган булса, ике сыйныф арасындагы көрәш сурәтләндерелгән. Г. Нигъмәти [11, б. 341].

Лингвистикада мәгънә формалаштыру механизмын тел билгесенең валентлыгы төшенчәсе, ягъни аерым билгенең башка билгеләр белән бәйләнешкә керү сәләте белән бәйлиләр. Валентлыкның ике төре карала: системалылык, яки схемага (грамматикага) буйсынуны күздә тоткан конструктив-техник валентлык һәм стихиялелек яки интерпретатив-мәгънәви валентлык, ул тулаем телгә дә, тел системасының теләсә кайсы элементына, сөйләм формалашуына, ягъни текстка да карарга мөмкин.

«Сугыш» концепты татар теле дөнья сурәтендәге мәгънәсе буенча якын булган башка концептлар белән үзара бәйләнештә булуы ачыкланды. Әлеге бәйләнешләр лексикографик чыганакларда теркәлгән лексик берәмлекләр ярдәмендә дәлилләнә: *сугыш, көрәш, бәрелеш, орыш, кыйнаш, үлем уены, яу, дау, кул сугышы, бәйге, ярыш, арка сугыш, сугыш кыры, сугыш алласы, фронт, гаскәр, илбасар, атыш, сугыш уены, фикерләр капма каршылыгы, кырылыш, алыш, эчке көрәш.*

Китерелгән мисаллар *сугыш* мәгънәсе белән бәйләнгән, ягъни якларның каршы торуын күрсәтә һәм безнең тарафтан тикшерелә торган концептның ассоциатив кырын тәшкил итә. Кырлар аша сөйләүченең аңында бик күп концептуаль күзаллаулар актуальләшә. Сүзләр арасындагы ассоциатив бәйләнешләр очраклы түгел, алар кешенең танып белү эшчәнлеге белән туры килә.

Фигыльләр белән валентлык модельләрен аерып алу татар телендә конфронтация үсеше идеясен белдерә торган фигыльләрнең шактый зур төркем булуын ачыкларга ярдәм итте: *(сугыш) башлау, (сугыш) ачу, (сугыш уты) кабызу, каршы тору, сугыш халәтендә булу; сугыш хәрәкәтләре алып бару, бәрелешү, пычакка-пычак килү, (сугыш) игълан итү, сугышу, көрәшү, көч сынашу, атакалау, басып керү, яулап алу, кырып ташлау, утка тоту, тар-мар итү, (утка) ташлану, кораллану, (сугышка) керү, (сугышта) һәләк булу, сугышып алу, һөҗүм итү, (сугышта) катнашу, (сугыштан) чыгу, кайту, (сугышка) өндәү, (сугышка) омтылу, (сугыш) теләү, (сугышны) пропагандалау, (сугышка) ыргылу, атакалау, штурмлау, (сугышны) оту, (сугышта) җиңү, хәбәрсез югалу (сугышта), (сугыш) кичү,*

*(сугыш) күрү, (сугышта) ятып калу, үлеп калу* һ.б.

Сугыш билгеләре ике зур төркемгә аерыла: 1. Сугышны тискәре яктан характерлый торган сыйфатлар: *вәхшәтле, гаделсез, канлы, дәһшәтле, рәхимсез, аяусыз, югалтулы, ачы (сугыш), салкын, империалистик;* 2. Сугышны уңай характерлый торган сыйфатлар: *данлы, бөек, изге, гадел.* Сугышны уңай яктан характерлый торган сыйфатлар тискәре сыйфатларга караганда күпкә азрак.

Мисаллар нигезендә сугышның түбәндәге төрләрен аерып чыгарырга мөмкин: сыйнфый көрәш, салкын сугыш, изге, колониаль, локаль.

Изафәнең беренче төре нигезендә барлыкка килгән сүзтезмәләр: *бөтендөнья сугышы, гражданнар сугышы, атом-төш сугышы, яулап алу сугышы, азат итү сугышы, басып алу сугышы, ватан сугышы, бандитлар сугышы, дөреслек сугышы, диңгез сугышы, су асты сугышы, һава сугышы, штык сугышы, разведка сугышы, һөҗүм сугышы, партизаннар сугышы, йодрык сугышы, бәйсезлек сугышы, атом-төш сугышы* һ. б.

«Краткий русско-татарский словарь военных терминов (толмач)» та сугышның өстәмә мәгънәләре бирелә: «узь ара сугӧшӧ, партизан сугӧшӧ, мина сугӧшӧ, qор сугӧшӧ, тау сугӧшӧа, köче сугӧш» [4, б. 63].

«Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге»ндә сугышның гражданская – гражданнар сугышы, захватническая – басып алу сугышы, маневренная – маневрлы сугыш, партизанская – партизаннар сугышы, холодная – салкын сугыш, ядерная – атом-төш сугышы төрләре бирелгән [5, б. 47].

«Татарча-русча хәрби лексика сүзлегендә» Р.Т. Сәфәров *сугыш* лексемасына түбәндәге сүзлек мәкаләсен тәкъдим итә: 1) война. *Җитмәсә, менә ничә еллар инде илнең көнбатышында поляк һәм литвалылар белән сугыш бара, шведлар урысларга каршы күтәрелә, Кырым ханы килеп, бөтен Мәскәүне яндырып китте, бер Кремль генә утырып калды.* Ф. Бәйрәмова; 2) сражение, битва; бой; **кул сугышы** рукопашный бой. *Әмма яугир артыннан яугир ава башлагач, эш кул сугышына да барып җитте, кылыч һәм хәнҗәрләр хәрәкәткә килде.* Ф. Бәйрәмова; **сугыш аты** боевой конь; **сугыш балтасы** боевой топор. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р. Фәхретдинов; **сугыш кыры** поле битвы. *Казанлылар гомер-гомергә сугыша белмәделәр, сәүдә итәргә яраттылар, сугыш кырында орышу алар өчен ят нәрсә, хәзер дә әллә ни үзгәрмәгәннәрдер.* М. Хәбибуллин. *Җитмәсә, иштәк-вогулларның барысы да диярлек сугыш кырыннан качып беткән, аларны инде Искәр тирәсендә эзләп табарлык та түгел...* Ф. Бәйрәмова; **сугыш мәйданы,. сугыш кыры**. *Бу ут яңгырына иң беренче булып иштәк-остяклар түзмәде, алар, акрынлап, агачлар арасына йөгерделәр, аннан бөтенләй сугыш мәйданын ташлап качтылар.* Ф. Бәйрәмова; **үзара сугыш, эчке сугыш**. *Үзара сугышлар, урман даладагы ялгыз тормыш безнең халыкны тагы кыргый хәлгә төшермәсме дип куркам.* Ф. Бәйрәмова; **эчке сугыш** гражданская война; междоусобица. *Эчке сугышлар сәбәпле, монда күп нәрсә бозылган, дәүләт тотуның рәте киткән, җитмәсә, халык та диннән-гыйлемнән шактый читләшкән булып чыкты.* Ф. Бәйрәмова [9, б. 86].

Бай хәрби тәҗрибә тематик терминологиядә чагылыш таба. Ләкин вакыт үтү белән хәрби терминология дә үзгәрә, кайбер сүзләр актуальлеген югалта, яңа терминнар барлыкка килә. Бөек Ватан сугышыннан соң кораллы көчләрдә булган зур үзгәрешләр телгә яңа сүзләр, төшенчәләр һәм терминнар кертте. Сугыш белән бәйле күзаллаулар тел шәхесенең аңында шулай ук үзгәрә. Украина белән бәйле соңгы хәрби вакыйгалар безнең телгә «махсус хәрби операция», «пилотсыз очу аппараты», «кызыл линия» кебек бөтенләй яңа сүзләр, терминнар кертте. Яңа һөнәр барлыкка килде – БПЛА операторы. Инде онытыла башлаган мобилизация сүзе яңадан активлашты. Вакыйгалар тел аңыбызга билгеле бер йогынты ясады һәм өйрәнелә торган концептның бөтенләй яңа интерпретациясен барлыкка китерде. Алдарак сугыш кыры билгеләрен уңай һәм тискәре яктан сыйфатлана торган төркемнәргә бүлеп карасак, Махсус хәрби операцияне уңай яки тискәре яктан характерлый торган билгеләр табылмады. Димәк, ул үзе генә өченче – нейтраль төркемне барлыкка китерә.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, концептны тулырак ачу өчен, тикшерелә торган материал сыйфатында вокабулаларны гына түгел, ә гыйбарәләрне препарацияләүне дә файдаланырга кирәк. Л.О. Чернейко фикеренчә,

«үзеннән-үзе оешкан, әзерлексез сөйләм аеруча кыйммәткә ия, чөнки нәкъ менә ул тел дөньяга мөнәсәбәтне, дөрес бәяне күрсәтә. Моннан тыш, мәдәни әһәмиятле берәмлекләрне аерып күрсәтергә мөмкинлек бирә, алар өчен вокабулалар фигураны чагылдыра торган фон булып торалар» [13, б. 7].

«Сугыш» концепты ялгызлык исемнәр белән дә ачыла – *герман сугышы*: «Кемнәрдер бәет борынгы түгел, аны теге *герман сугышы* беткәндә Австриядән әсирлектән кайткан солдатлар гына чыгарган дип бәхәсләшәләр...» (А. Гыйләҗев); *фин сугышы*: «Шул елларда *фин сугышы* башланып китә» (Н. Дәүли); *әфган сугышы:* «*Әфган сугышы* – совет дәүләте тарихында иң катлаулы сәхифәләрнең берсе. Аның турында күп ишетелгән. Әфган сугышы турында күп язылган» (Я. Шафиков); *вьетнам сугышы:* «...*Вьетнам сугышы* дип искә алынган сугышта була» (Социалистик Татарстан); *чечня сугышы:* «Ни өчен *чечня сугышы* турында бәетләр юк?»; *кавказ сугышы:* «...Европа ул вакытта *Кавказ сугышына*, хәзерге кискен карашлар белән чагыштырганда, бик сүрән, чытык чырай белән карый» (Шәһри Казан); соңгы елларда вакытлы матбугатта, сөйләм телендә *украина сугышы* дигән гыйбарә барлыкка килде [14, б. 88].

В.А. Масловага ияреп [15, б.187-188], сугышка караган эпитетларны без берничә семантик төркемгә бүлдек: *гадел, прогрессив сугыш*: изге сугыш, гадел сугыш, данлы сугыш, бөек сугыш, азат итү сугышы; бәйсезлек сугышы, дөреслек сугышы; *гадел булмаган, реакцион сугыш:* басып алу сугышы, империалистик сугыш, мәгънәсез сугыш, аяусыз сугыш, кансыз сугыш, бандитлар сугышы, рәхимсез, яулап алу сугышы; *дәвамлы, колачы сугыш*: бөтендөнья сугышы, ватан сугышы, глобаль сугыш, локаль сугыш; *сугышның авырлыгы, характеры, нәтиҗәсе:* вәхшәтле сугыш, дәһшәтле сугыш; канлы сугыш, ачы сугыш, югалтулы сугыш; *сугышның фәндәге билгеләмәләре:* атом-төш сугышы, йодрык сугышы; партизаннар сугышы, диңгез сугышы, су асты сугышы, һава сугышы, штык сугышы, разведка сугышы, һөҗүм сугышы, салкын сугыш.

Күргәнебезчә, сугышны тискәре характерлый торган эпитетлар чагыштырмача күбрәк, бу сугышны кешеләрнең аңында тискәре кабул итү, сугышны хупламау турында сөйли.

*Сугыш* сүзенең аңлатмаларын анализлау «Сугыш» концептының түбәндәге үзенчәлекле билгеләрен ачыкларга мөмкинлек бирә: 1. Тынычлык булмау, ызгыш-талаш, низаг, дәүләтләр арасында яки бер дәүләт эчендә социаль төркемнәр һәм аларның аерым вәкилләре арасында кораллы көрәш. 2. Мөнәсәбәтләрдә киеренкелек, коралланмаган конфликт, үз идеологиясен көчләп тагарга омтылу. 3. Кешеләр арасындагы дошманлык, ызгыш, талаш, сугышу. 4. Капма-каршылыкларның, карашларның, омтылышларның, фикерләрнең бәрелеше. 5. Ярыш. 6. Җиңү, яулап алу, хакимият алу теләге, омтылышы. 7. Уен. 8. Махсус оештырылган, махсус бер максаты булган хәрбия операция, чара.

Татар теленең лексик берәмлекләре күрсәткәнчә, «Сугыш» концепты киң кулланылышлы. Татар дөнья тел сурәтендә «Сугыш» концептының актуаль, күпкырлы булуын, бүгенге көндә дә татар телендә сөйләшүчеләрнең аңында әһәмиятле роль уйнавын күрсәтә. Югарыда санап үтелгән мисаллар тикшерелә торган концептның милитаристик характерын – аның универсаль әһәмиятен ача.

Концептның этномәдәни үзенчәлеге шунда: төрки халыклар сугыш темасына зур әһәмият бирсәләр дә, «борынгы мәҗүсилек чорында сугыш алласы булу – сугышны изге дип санауга дәлил була алмый» [9, б. 22]. Татар халкы аңында «Сугыш» концепты, сугышны фаҗигале күзаллауга бәйле рәвештә, семантик-ассоциатив структураның катлаулы моделен тәшкил итә. Сугышка явызлык, кешелексезлек, аморальлек, хаос, кайгы, үлем, югалту коннотацияләре бирелә.

«Сугыш» концептының семантик характеристикаларын диахрон планда өйрәнү буыннар арасындагы кыйммәтләр системасында барлыкка килгән үзгәрешләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, «Сугыш» концептын тикшерү әлеге концептның күп үлчәмле күренеш булуын, телдә бер мәгънәгә генә ия булмавын, үз эчтәлеген төрле тел катламнарында төрлечә чагылдырырга сәләтле булуын күрсәтте. Татар телендә хәрби лексиканың формалашуы күп гасырлар дәвамында барган, бүгенге көнгә кадәр тулылануын һәм баюын дәвам итә. Хәрби лексикага кергән атамалар техниканы камилләштерү, коралның яңа төрләре барлыкка килү һ. б. белән тыгыз бәйләнгән. шул ук вакытта фәнни-техник прогресс үсеше халыкларның яшәү рәвешендә дә котылгысыз үзгәрешләр китереп чыгара, бу исә лексиканың тулы бер тематик төркемнәренең юкка чыгуына китерә.

Тикшеренү барышында ирешкән нәтиҗәләр, татар теле концептосферасын җентекләбрәк тасвирлау өчен нигез булырлык мәгълүматлар алырга мөмкинлек бирер дип уйлыйбыз.

**Әдәбият**


1. Маслова В.А., Бахтикиреева У.М. Лингвокультурологический анализ. Москва: Издательство Юрайт, 2022. 311 с.
2. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. М.: Гуманит. издат. центр «ВЛАДОС»; Казань: Магариф, 2004. 346 с.
3. Красавский Н.А. Эмоциональные концепты в немецкой и русской лингвокультурах. Волгоград, 2001. 422 с.
4. Краткий русско-татарский словарь военных терминов (толмач). М.: Искра революции, 1926. 176 с.
5. Мугинов Р.А. Русско-татарский словарь военных. Казань: Тат. кн. изд-во, 2000. 150 с.
6. Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков: (общетюркские и межтюркские основы на гласные). М.: Наука, 1974. 768 с.
7. Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазе язмаларының үзенчәлекләре. Казан: Казан унты нәшр., 1981. 162 б.
8. Сафаров Р.Т. Военная лексика татарского языка. Казань: ИЯЛИ, 2015. 196 с.
9. Сәфәров Р.Т. Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2017. 112 б.
10. Тимергалин А. Миллият сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 575 б.
11. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 2 том. Казан: Татар кит. нәшр., 1979. 726 б.
12. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999. 256 б.
13. Чернейко Л.О. Лингвофилософский анализ абстрактного имени. М., 1997. 320 с.
14. Зиатдинова Г.И. Концепт «Сугыш (Война)» в татарской языковой картине мира. Казань: Ихлас, 2010. 168 с.
15. Маслова В.А. Когнитивная лингвистика. Минск: ТетраСистемс, 2008. 266 с.


---

# РОЛЬ ЛИНГВОКУЛЬТУРНОГО КОНЦЕПТА «ВОЙНА» В ТАТАРСКОМ НАЦИОНАЛЬНОМ СОЗНАНИИ


**Гульназ Иршатовна Зиятдинова**,
Казанский национально-исследовательский
технический университет им. А. Н. Туполева – КАИ,
Россия, 420015, г. Казань, ул. Б. Красная, д. 55,
ggulnaz0507@mail.ru.

**Альфия Шавкетовна Юсупова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
alyusupova@yandex.ru.

**Фируза Рамзилевна Сибгаева**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
FiruzaRS88@ yandex.ru.



В статье раскрываются особенности репрезентации концепта «война» в татарском языке. Материалом для анализа послужили лексикографические источники. Цель исследования – выявить семантические, лингвокультурные, ассоциативные компоненты, входящие в семантическую структуру данного концепта. Доказано, что концепт «война» имеет сложную структуру, состоящую из разных групп признаков.



**Ключевые слова:** татарский язык, концепт «война», языковая картина мира, национальная концептосфера, художественный текст

**Для цитирования**: Зиятдинова Г. И., Юсупова А. Ш., Сибгаева Ф. Р. Роль лингвокультурного концепта «война» в татарском национальном сознании // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 21–33. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-21-33